**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләре буенча республика эксперт төркеме составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләре буенча республика эксперт төркеме турында» 2012 елның 2 июнендәге ПУ-415 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 9 сентябрендәге ПУ-868 номерлы, 2013 елның 11 декабрендәге ПУ-1211 номерлы, 2014 елның 17 ноябрендәге ПУ-1055 номерлы, 2015 елның 27 ноябрендәге ПУ-1130 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы, 2017 елның 2 декабрендәге ПУ-1043 номерлы, 2018 елның 9 февралендәге ПУ-151 номерлы, 2018 елның 31 мартындагы ПУ-273 номерлы, 2018 елның 8 августындагы ПУ-557 номерлы, 2020 елның 2 маендагы ПУ-266 номерлы, 2021 елның 2 июнендәге ПУ-425 номерлы, 2022 елның 10 мартындагы ПУ-196 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 23 сентябрендәге 667 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләре буенча республика эксперт төркеме (алга таба – эксперт төркеме) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

эксперт төркеме составыннан З.Р. Вәлиеваны, М.М. Миңнуллинны, Л.Ә. Таишеваны, М.Җ. Фәйзрахмановны, А.М. Хәйретдиновны, А.В. Шадриковны чыгарырга;

эксперт төркеме составына кертергә:

Абашев Альмир Рәшит улын – Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрын;

Әюкасов Рөстәм Анатольевичны – Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директорын;

Җиһаншин Азат Илдус улын – Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрын;

Терентьев Александр Михайловичны – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисен (килешү буенча).

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2026 ел, 05 март
№ 175